КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 20 гыйнвар г.Казань № 20

«Созвездие – Йолдызлык» еллык ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивален үткәрү турында

Татарстан Республикасының иҗади сәләтле балаларын һәм талантлы яшьләрен эзләү, үстерү, аларга ярдәм итү, шулай ук балалар һәм яшьләр иҗатына булышлык күрсәтү, яшьләр мохитендә милли, мәдәни һәм рухи кыйммәтләрне үстерү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм иҗтимагый оешмалары көчләрен берләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының, Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Созвездие – Йолдызлык» Татарстан Республикасы төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы, «АРТИАС» иҗади хезмәткәрләр берләшмәсе» Казан шәһәр иҗтимагый оешмасы, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәдәниятне үстерүгә булышлык күрсәтү фонды, «Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе, «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционерлар җәмгыяте белән берлектә, «Созвездие – Йолдызлык» еллык ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивален (алга таба – «Созвездие – Йолдызлык» фестивале) үткәрү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

«Созвездие – Йолдызлык» еллык ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивален үткәрү турындагы нигезләмәне;

«Созвездие – Йолдызлык» еллык ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивален әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составын.

3. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына «Созвездие – Йолдызлык» фестивален әзерләү һәм үткәрү барышын массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны тәэмин итәргә.

4. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына «Созвездие – Йолдызлык» фестивален үткәрү урыннарында гражданнар иминлеген һәм иҗтимагый тәртипне тәэмин итүдә чараны оештыручыларга булышлык күрсәтүне;

«Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционерлар җәмгыятенә «Созвездие – Йолдызлык» фестивален әзерләү һәм үткәрү барышын яктыртуны тәэмин итүне;

Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре башлыкларына «Созвездие – Йолдызлык» фестиваленең зона этапларын оештыруда һәм үткәрүдә булышлык күрсәтүне.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин